ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 21 « октябрь 2024 ел № 764

**2025 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елга кушымта нигезендә түбәндәгене расларга:

Арча муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне матди карап тотуга норматив чыгымнарны.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнә әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә, мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
21.10. 2024 ел, № 764
карары белән расланды

**Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне матди карап тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территория ягыннан урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә елына норматив чыгымнар |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 118 316 |
| | авыл җирлеге | 119 559 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 177 385 |
| | авыл җирлеге | 181 658 |